**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Keче Салтык авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**«21» май 2019 ел** **№ 124**

**Татарстан Республикасының Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советының 2017 елның 14 ноябрендәге 71 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советының 2017 елның 14 ноябрендәге 71 номерлы «Җир салымы турында " карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:»:

6 статьяның икенче абзацында «1 ноябрьгә кадәр» сүзләрен «31 декабрьдән дә соңга калмыйча»сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Салтык авылы, Бакый Урманчы урамы, 9;
- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Мәрәтхуҗа авылы, Вахитов урамы, 9, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Кече Салтык авыл җирлеге Башлыгы,**
**Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Кече Салтык авыл җирлеге Советы рәисе** **А.Г.Җиһаншин**